**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.02.2021 № 154

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының административ регламентларын раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге 1055 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге тарафыннан гражданлык хәле актын теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү өчен һәм 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы (2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән) нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының административ регламентларын раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге 1055 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү

бүлеге тарафыннан гражданлык хәле актын теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4 пунктта түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«Гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу өчен нигез булган документлар (1-6 нчы кушымталар).»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин